**Казан шәһәре Башкарма Комитетының**
**2024 елның 25 июлендәге 3109 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге «2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаның эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге 3240 номерлы «2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа турында» карарына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 22 ноябрендәге 3615 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге 3240 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга».

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 25 июлендәге 3109 номерлы карарына кушымта

**2024-2030 елларга Казан шәһәрендә**
**гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа**

## I. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2014-2023 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа (алга таба – Программа) |
| Программа координаторы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге |
| Муниципаль заказ бирүчеләр | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты |
| Программаны төзүчеләр | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге |
| Программаны башкаручылар | Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак һәм территориаль органнары; предприятиеләр, учреждениеләр һәм иҗтимагый оешмалар |
| Программаның максаты | Казан шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту |
| Программаның бурычлары | 1. Милләтара, конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга ярдәм итү.<br>2. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара бәйләнешен камилләштерү.<br>3. Гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тиңдәшлеген формалаштыру, милләтара аралашу культурасын тәрбияләү.<br>4. Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен саклау һәм яклау, шулай ук туган телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар булдыру. Татарстан Республикасы законнары нигезендә Казанда Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез кулланылышын тәэмин итү.<br>5. Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни яктан һәм тел ягыннан күптөрлелеген саклап калу һәм аларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2024-2030 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм | Программаны финанслау күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабыннан 54,790 млн сум тәшкил итә: |

| | |
|---|---|
| чыганаклары | - 2024 елда – 25,370 млн сум;<br>- 2025 елда – 4,820 млн сум;<br>- 2026 елда – 4,820 млн сум;<br>- 2027 елда – 5,320 млн сум;<br>- 2028 елда – 4,820 млн сум;<br>- 2029 елда – 4,820 млн сум;<br>- 2030 елда – 4,820 млн сум.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз буларак бирелә һәм аларга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | Шәһәрдә шәһәр халкының милләтара мөнәсәбәтләрне уңай бәяләүче өлеше 2030 елда кимендә 75% тәшкил итәчәк.<br>Шәһәрдә шәһәр халкының динара мөнәсәбәтләрне уңай бәяләүче өлеше 2030 елда кимендә 80% тәшкил итәчәк.<br>Башка милләт вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәт дәрәҗәсе 2030 елда кимендә 90% тәшкил итәчәк.<br>Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә һәм тел төрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны 2030 елда 700000 кеше тәшкил итәчәк.<br>Төп нәтиҗә – социаль-сәяси тотрыклылыкны, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, этномәдәни үзенчәлекләрне саклап калу һәм Казан шәһәрендә яшәүче халык вәкилләренең социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү. |

## II. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә, шул исәптән программаны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларга характеристика

Татарстан Россия Федерациясенең күпмилләтле һәм күпконфессияле булуы ачык күренеп тора торган, әлеге территориядә күп гасырлар дәвамында формалашкан субъекты булып тора.

Татарстан Республикасы Россиянең иң күпмилләтле территорияләренең берсе булып тора, биредә 173 тән артык милләт вәкиле яши.

Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру мәсьәләләре системалы, комплекслы характерда һәм барлык хакимият органнары игътибарында тора. Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эш өчен җаваплы, милли һәм дини иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә торган ведомствоара координация советлары, эшче төркемнәр төзелде һәм эшли.

Казан – 115 тән артык милләт яши торган күпмилләтле республика башкаласы. Казан шәһәренең төп этник төркемнәре: руслар, татарлар, чувашлар, украиннар, азәрбайҗаннар, марилар һәм башкалар.

Татарстан башкаласында барлыгы 200 дини оешма: 97 ислам, 57 православие, 4 старовер, 1 католик, 1 әрмән апостоллыгы, 34 протестант, 1 мормон, 2 яһүд, 1 бахая, 1 кришнаит һәм 1 буддизм оешмасы эшләп килә.

Бүген Казанда 149 гыйбадәт объекты бар: 75 мәчет, 51 православие гыйбадәтханәсе, 5 старовер гыйбадәт объекты, христиан юнәлешендәге 15 чиркәү, 1 синагога, Бахая һәм Кришна гыйбадәт йортлары.

Казан шәһәрендә 1999 елның 26 маенда Халыклар дуслыгы йорты ачылды, ул 2012 елда яңа бинага күченде. Бу Казандагы уникаль учреждение, аның максаты – иҗтимагый милли-мәдәни оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү. Ул төрле халык вәкилләренә милли үзаңнарын ныгытырга, иҗади потенциалларын үстерергә мөмкинлек бирә. Халыклар дуслыгы йортында Татарстан халыклары ассамблеясенең 39 халыкны һәм этник төркемнәрне берләштергән күпмилләтле гаиләсе урнашкан.

Россия Федерациясенең күпмилләтле субъектларының берсе буларак Татарстан һәм Казан милләтара мөнәсәбәтләрдә тотрыклылыкны һәм гармонияне саклый.

Әлеге хәлләр төбәкнең туристик яктан җәлеп итүчәнлегенә тулаем уңай йогынты ясый, ә милләтара мөнәсәбәтләрне яхшырту һәм Программаны кабул итү белән тәэмин ителгән вазгыятьне тотрыклыландыру буенча планлы эш туризмны тагын да үстерүгә ярдәм итәчәк.

Соңгы елларда Казанда югары дәрәҗәдә дистәләгән эре халыкара спорт ярышлары – дөнья һәм Европа чемпионатлары үткәрелде, бу туристлар агымының актив артуына китерде. XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада һәм футбол буенча ФИФА Дөнья чемпионаты төбәктә туризм үсешенә яңа этәргеч бирде. Шуңа бәйле рәвештә, уңай милләтара һәм конфессияара мохит булдыруны тәэмин итеп, әлеге тенденцияне саклап калырга кирәк.

Моннан тыш, Казан элеккечә хезмәт мигрантларын җәлеп итә торган төбәк булып кала бирә. Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр кырында уңайлы икътисади вазгыять һәм тынычлык кешеләргә шәһәребезне акча эшләү яисә гаилә белән даими яшәү мәйданчыгы буларак сайларга этәргеч бирә. Әлеге факторлар мигрантларның һәм кабул итүче якның мәдәни-көнкүреш өлкәсендә үзара ихтирамлы мөнәсәбәтләрен тәэмин итә торган чаралар системасын камилләштерүне күздә тота.

Программаның актуальлеге милли сәясәтне гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләренә ярдәм итү буенча булган шәһәр тәҗрибәсен анализлау эшен дәвам итүнең аеруча мөһим булуы белән аңлатыла.

Программа «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы законы нигезендә эшләнгән һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 16 маендагы 2631 номерлы карары белән расланган 2014-2023 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә торган эшне дәвам итәргә тиеш.

Программа:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 нчы номерлы карары белән расланган «2014-2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «2023-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 августындагы 730 номерлы карары белән расланган «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә эшләнгән.

## III. Программаның максатлары һәм бурычлары, программа чаралары. Фаразланган ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау, Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа Татарстан башкаласында яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен саклап калу, уңай якка үстерү, аларга ирешү юллары һәм моның өчен кирәкле оештыру шартлары, интеллектуаль, мәгълүмати һәм матди-финанс ресурслары өчен кирәкле шартларны тәэмин итү максатларын, бурычларын билгели торган документ булып тора (1 номерлы кушымта).

Программаның максаты – Казан шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны, татулыкны ныгыту.

Программаның бурычлары:

- милләтара һәм конфессияара тынычлыкны, татулыкны тәэмин итү, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга ярдәм итү;

- дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

- гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген формалаштыру, милләтара аралашу мәдәниятен тәрбияләү;

- Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен саклау һәм яклау, шулай ук туган телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру. Татарстан Республикасы законнары нигезендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез эшләвен тәэмин итү;

- Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау, яклау өчен шартлар тудыру.

Программаның төп чаралары – милләтара һәм конфессияара тынычлыкны, татулыкны тәэмин итүгә, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар; дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара бәйләнешен камилләштерү чаралары; гражданнарда толерант аң һәм үз-үзеңне тотышын формалаштыруга, милләтара аралашу культурасын тәрбияләүгә юнәлтелгән чаралар; Татарстан Республикасы законнары нигезендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез эшләвен тәэмин итү чаралары; Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклап калу, аңа ярдәм итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар.

Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре:

- шәһәр халкының шәһәрдә милләтара мөнәсәбәтләрне уңай бәяләүче өлеше 2030 елда кимендә 75% тәшкил итәчәк;

- шәһәр халкының шәһәрдә динара мөнәсәбәтләрне уңай бәяләүче өлеше 2030 елда кимендә 80% булачак;

- башка милләт вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәт дәрәҗәсе 2030 елда кимендә 90% тәшкил итәчәк.

- Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә һәм тел төрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны 2030 елда 700000 кеше тәшкил итәчәк.

Программаның максат индикаторлары Программаның 2 номерлы кушымтасында бирелгән.

Программа 2024 елдан 2030 елның декабренә кадәр гамәлгә ашырыла.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чараларын финанслау нигездә Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабыннан гамәлгә ашырыла. Шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар җәлеп итү планлаштырыла.

Программаны финанслау күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабыннан 54,790 млн сум тәшкил итә:

- 2024 елда – 25,370 млн сум;
- 2025 елда – 4,820 млн сум;
- 2026 елда – 4,820 млн сум;
- 2027 елда – 5,320 млн сум;
- 2028 елда – 4,820 млн сум;
- 2029 елда – 4,820 млн сум;
- 2030 елда – 4,820 млн сум.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларын бурычлар буенча бүлү Программаның 3 номерлы кушымтасында бирелә.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларын башкаручылар арасында бүлү Программаның 4 номерлы кушымтасында бирелә.

Финанслау күләмнәре фаразлау рәвешендә һәм аларга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программа чаралары максатчан акчалар бүленмичә дә башкарылырга мөмкин.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның координаторы – Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге, ул Программаны башкаручылар белән берлектә:

- билгеләнгән тәртиптә Программа чаралары исемлегенә, аларны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарга төгәллек кертү буенча, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру механизмы турында тәкъдимнәр әзерли;
- максатчан индикаторлар исемлеген аныклый;

- кирәк булганда билгеләнгән тәртиптә Программаны раслау турында норматив хокукый актка тиешле үзгәрешләр кертә;

- квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосына кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 нче номерлы карарының 3 нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе Программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- елга ике тапкыр (15 июльгә һәм 15 гыйнварга) Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарына Программа чараларын үтәү буенча хисап тапшыра;

- ел саен хисап чорыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат әзерләп, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә җибәрә;

- ел саен 15 гыйййнварга кадәр, Программаны гамәлгә ашыру барышы турында хисап әзерли һәм Казан шәһәр Думасының Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә тапшыра.

Программаны башкаручылар квартал саен хисап чорыннан соң килә торган айның 15 нче көненә кадәр Программаның координаторына Программа чараларын башкару турында мәгълүмат бирә.

## VI. Программаны гамәлгә ашыруның социаль эффективлыгын бәяләү

Программаны гамәлгә ашырудан барлыкка килгән социаль эффективлык Казан шәһәрендә яшәүче халык вәкилләренең социаль тотрыклылыгын, этносара һәм конфессияара тынычлыгын, татулыгын, этномәдәни үзенчәлеген саклаудан һәм социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт һәм түбәндәгеләрдә чагыла:

- гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тиндәшлеген ныгытуда;

- этномәдәни потенциалны файдалануның эффективлыгы артуда;

- милләтара һәм динара низаглар килеп чыгуга юл куймауда;

- чит ил гражданнарын (мигрантларны) социомәдәни адаптацияләүне һәм интеграцияләүне камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар системасын гамәлгә ашыруда.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказ бирүче тарафыннан башкарыла. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программаның максатына һәм бурычларына ирешү дәрәҗәсеннән чыгып, ресурслар белән тәэмин ителеш Программаның планлаштырылган чыгымнар дәрәҗәсенә туры килгәндә, максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең фактта ирешелгән күрсәткечләрен һәм аларның план буенча күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән бәяләнә.

Программага
1 номерлы кушымта

**2024–2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаның максаты, бурычлары, программа чаралары**

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| **Максат – Казан шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту** | | | | | | | | | | |
| **1 нче бурыч. Милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга ярдәм итү** | | | | | | | | | | |
| 1.1. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында уздырыла торган чаралар турында мәгълүмат урнаштыру:<br>- этникара һәм динара мөнәсәбәтләрне ныгытуга;<br>- дини һәм этник түземсезлеккә һәм дискриминациягә каршы торуга ярдәм итә торган. | ТКӨМСГАБ, Мәгариф идарәсе, ММЧ белән элемтәләр бүлеге (килешү буенча), Казан шәһәре иҗтимагый үзәге | Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырылган язмалар саны, берәмлекләрдә | 55 | 56 | 56 | 57 | 57 | 60 | 60 | 62 |

| Программа чаралары | Башкаручы лар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1.2. Ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү өчен түбәндәге темаларга курслар, семинарлар, тренинглар оештыру һәм үткәрү:<br>- экстремизмны һәм терорчылыкны профилактикалау;<br>- коммуникацияләр һәм корпоратив культура;<br>- эмоциональ интеллектны үстерү;<br>- конфликтология. | Кадрлар сәясәте идарәсе, милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге, иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге, район администрац ияләре, К(И)ФУ (килешү буенча) | Укыган кешеләр саны, кеше. | - | 30* | 30* | 30* | 30* | 30* | 30* | 30* |
| 1.3. Социаль, хәйрия чаралары, өмәләр, интервьюлар, түгәрәк өстәлләр һәм башка чаралар кысаларында уртак эшне гамәлгә ашырганда РПЧ һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Татарстан | Иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге, оештыру идарәсе, РПЧ | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 5 | 5 | 5 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| митрополиясенә ярдәм күрсәтү | митрополиясе (килешү буенча), РИИ (килешү буенча), ТР ТР МДН (килешү буенча), КРС (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 1.4. Казан шәһәрендә бу өлкәдә конфликтлы ситуацияләрне булдырмау максатында дини ситуациягә, дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләргә ай саен мониторинг үткәрү | Иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге, Казан шәһәре иҗтимагый үзәге | Мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмати-аналитик материаллар саны, бер. | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| 1.5. Дини оешмалар һәм гыйбадәт корылмалары турында белешмәләр банкын төзү һәм актуальләштерү | Иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге, ҖһММК, Капиталь | Мәгълүмат базалары яңартылу саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | төзелеш һәм реконструкция идарәсе | | | | | | | | | |
| 1.6. «Казан шәһәренең иң яхшы дини объектлары» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Иҗтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге, Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре иҗтимагый үзәге, Туризмны үстерү комитеты, РПЧ митрополиясе (килешү буенча), РИИ (килешү буенча), ТР ТР МДН (килешү буенча) | Катнашучылар саны, дини объектлар | - | - | - | - | 50 | - | - | - |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1.7. Православие һәм мөселман мәдәниятләре нигезләрен белү буенча ел саен үткәрелә торган конкурслар оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе, ТР МДН (килешү буенча), РПЧ митрополиясе (килешү буенча) | Катнашучылар саны, кеше | 195 | 195 | 195 | 197 | 197 | 200 | 200 | 200 |
| 1.8. Казан шәһәренең мөселман һәм православие яшьләре катнашында спартакиада уздыруда ярдәм күрсәтү | ФКһСК, ИОБҮББ, РПЧ митрополиясе (килешү буенча), ТР МДН (килешү буенча), | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 150 | 150 | 155 | 155 | 160 | 160 | 160 |
| 1.9. Мәктәп китапханәләренең сәнгать фондын тулыландыру | Мәгариф идарәсе | Комплектланган учреждениеләр саны, бер. | - | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* |
| 1.10. Милли музыка коралларын сатып алу | Мәгариф идарәсе | Комплектланган учреждениеләр саны, бер. | - | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* | 5* |
| 1.11. Гомуми белем бирү оешмаларының һәм өстәмә | Мәгариф идарәсе | Комплектланган | - | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| белем бирү учреждениеләренең ансамбльләре, сәнгать коллективлары өчен милли костюмнар сатып алу яисә тегү | | учреждениеләр саны, бер. | | | | | | | | |
| **2 нче бурыч. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү** | | | | | | | | | | |
| 2.1. Бәйрәм итү кысаларында чаралар үткәрү:<br>- Халыкара туган тел көне (21 февраль);<br>- Туган тел көне (26 апрель);<br>- Рус теле көне (6 июнь) | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, ТХА (килешү буенча) | Катнашучылар саны, мең кеше | 115 | 115 | 120 | 125 | 130 | 135 | 140 | 145 |
| 2.2. Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләрендә, укучыларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә этникара ярдәмләшүне, татулыкны пропагандалауга һәм милләтара мәдәни элемтәләрне ныгытуга юнәлдерелгән күргәзмәләр (сәнгать күргәзмәсе, фотокүргәзмә һ.б.) үткәрү | Мәдәният идарәсе, Мәгариф идарәсе | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 2.3. Татар теле курсларын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Үткәрелгән курслар саны | 3 | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* | 2* |
| **3 нче бурыч. Гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тиндәшлеген формалаштыру, милләтара аралашу культурасын тәрбияләү** | | | | | | | | | | |
| 3.1. Татарстан халыклары дуслыгы йорты базасында мәктәп укучылары өчен дуслык һәм татулык дәресләре үткәрү | Мәгариф идарәсе, ТХА (килешү буенча), ТХДЙ (килешү буенча) | Катнашучылар саны, мең кеше | 5,8 | 5,8 | 5,8 | 6 | 6 | 6,2 | 6,2 | 6,2 |
| 3.2. Казан шәһәрендә яшәүче халыклар телендә «Күпмилләтле Казан» темасына иң яхшы иншага конкурс үткәрү | Мәгариф идарәсе, күпмилләтле якшәмбе мәктәбе | Катнашучылар саны, кеше | 75 | 75 | 75 | 78 | 78 | 80 | 80 | 85 |
| 3.3. Татар теленә өйрәтә торган видеороликлар булдыру | Мәгариф идарәсе | Караулар саны, мең кеше | 1,5 | 1,5* | 1,5* | 1,7* | 1,7* | 2* | 2* | 2* |
| 3.4. «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 140 | 100* | 100* | 100* | 100* | 100* | 100* | 100* |
| 3.5. Татар телендә ачык хореография һәм спорт | Мәдәният идарәсе, ПһСД | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 1000* | 1000* | 1500* | 1500* | 2000* | 2000* | 2000* |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| дәресләре сериясен оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | |
| **4 нче бурыч. Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен саклау һәм үстерү, шулай ук туган телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру. Татарстан Республикасы законнары нигезендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез эшләвен тәэмин итү** | | | | | | | | | | |
| 4.1. Мәктәп укучылары арасында фәнни-гамәли конференцияләр оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе, «Мәгариф» ассоциациясе (килешү буенча), «Казан Рус милли-мәдәни берләшмәсе» ҖИО (килешү буенча), К(И)ФУ (килешү буенча) | Катнашучылар саны, мең кеше | 4,5 | 4,5 | 4,5 | 4,7 | 4,7 | 5 | 5 | 5 |
| 4.2. Рус язучыларының туган көненә багышланган чаралар циклын оештыру | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, «Казан Рус милли- | Катнашучылар саны, мең кеше | 95,0 | 95,0 | 95,0 | 96,0 | 96,0 | 96,5 | 96,5 | 96,5 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | мәдәни берләшмәсе» ҖИО (килешү буенча), ТХА (килешү буенча), ТХДЙ (килешү буенча), К(И)ФУ (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 4.3. Татар язучыларының, күренекле фән һәм сәнгать эшлеклеләренең юбилей даталарына багышланган чаралар циклын оештыру | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, «Мәгариф» ассоциациясе (килешү буенча), ТХА (килешү буенча), ТХДЙ | Катнашучылар саны, мең кеше | 95,0 | 95,0 | 95,0 | 96,0 | 96,0 | 96,5 | 96,5 | 96,5 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | (килешү буенча), К(И)ФУ (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 4.4. Гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә кергән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү | Эш башкару идарәсе | Мөрәҗәгать язылган телдә башкарылган документлар өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.5. Хисап чоры кысаларында урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә ясау һәм урнаштыру | ТКХК, район администрацияләре | Агымдагы елда урнаштырылган урам күрсәткеч-ләренең әлеге өлкәдә норматив актларга туры килүе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.6. Шәһәр транспортында халыкка мәгълүмати хезмәт күрсәтүне Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә оештыруда ярдәм итү | Транспорт комитеты | Татарстан Республикасы ике дәүләт телендәге автоинформаторлар белән тәэмин ителгән | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | | җәмәгать транспорты өлеше, % | | | | | | | | |
| 4.7. Шәһәр конкурслары үткәрү:<br>- «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен өйрәтү буенча иң яхшы мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе тәрбиячесе»;<br>- «Иң яхшы рус теле укытучысы»;<br>- «Иң яхшы татар теле укытучысы» | Мәгариф идарәсе, К(И)ФУ (килешү буенча), БТК БК (килешү буенча) | Катнашучылар саны, кеше | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 |
| 4.8. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы балалар арасында ел саен татар һәм рус телләрендә шәһәр күләмендә фән (математика, физика, химия, биология, география, җәмгыять белеме, Татарстан тарихы) олимпиадаларын үткәрү | Мәгариф идарәсе, К(И)ФУ (килешү буенча) | Катнашучылар саны, кеше | 390 | 390 | 390 | 400 | 400 | 410 | 410 | 410 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 4.9. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында шәһәр конкурслары үткәрү:<br>- «Татар кызы», «Татар егете»;<br>- «Добрый молодец», «Красна девица» | Мәгариф идарәсе, ТКӨМСГАБ, «Казан Рус милли-мәдәни берләшмәсе» ҖИО (килешү буенча), «Мәгариф» ассоциациясе (килешү буенча), БТК БК (килешү буенча) | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, меӊ кеше | 100 | 100 | 100 | 110 | 110 | 115 | 115 | 115 |
| 4.10. «Ягымлы яз» фестивален үткәрү | БһЯЭБК, Мәгариф идарәсе, ТКӨМСГАБ | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, меӊ кеше | 5 | 5,1 | 5,2 | 5,4 | 5,6 | 5,8 | 5,9 | 6 |
| 4.11. Казан шәһәренеӊ мәктәп командалары арасында татар телендә ШТК уенының «Казан лигасы»н үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, меӊ кеше | 700 | 700 | 700 | 710 | 710 | 720 | 720 | 720 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 4.12. Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре буенча шәһәр олимпиадасын үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 |
| 4.13. «Сәләтле буын» шәһәр конкурсын үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 |
| 4.14. «Сәйяр» шәһәр фестивален үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 700 | 700 | 750 | 750 | 800 | 800 | 850 | 850 |
| 4.15. «Тел сагында – ир-егетләр» проектын гамәлгә ашыру | Мәгариф идарәсе, БТК БК (килешү буенча) | Катнашучылар саны, кеше | 100 | 100 | 150 | 150 | 200 | 200 | 250 | 250 |
| 4.16. «Апуш» балалар театр студиясенең матди-техник базасын ныгыту | Мәдәният идарәсе | Комплектланган студияләр саны, бер. | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 |
| 4.17. Укытучылар һәм тәрбиячеләр, мәгариф оешмалары җитәкчеләре өчен семинарлар үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 1500 | 1500* | 1500* | 1500* | 1500* | 1500* | 1500* | 1500* |
| **5 нче бурыч. Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни һәм тел ягыннан күптөрлелеген саклап калу, аларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | | | | |
| 5.1. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның «Масленица», «Нәүрүз», «Сабантуй», | Мәдәният идарәсе, ТКӨМСГАБ, | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, | 55 | 55 | 55 | 56 | 56 | 56 | 57 | 57 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| «Кузьминки» гомумроссия һәм республикакүләм милли бәйрәмнәрен һәм башка чараларны уздыруда ярдәм күрсәтү | ТХА (килешү буенча), ТХДЙ (килешү буенча) | мең кеше | | | | | | | | |
| 5.2. «Татар яшьләре көннәре» Халыкара форумны үткәрүдә катнашу | БһЯЭБК, ТКӨМСГАБ, Мәгариф идарәсе, БТК БК (килешү буенча), ТХА (килешү буенча) | Катнашучылар саны, кеше | 190 | 190 | 190 | 190 | 190 | 190 | 190 | 190 |
| 5.3. Язучылар белән очрашулар оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе, Мәгариф идарәсе | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 210 | 210 | 210 | 210 | 210 | 210 | 210 | 210 |
| 5.4. Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында «Халыклар дуслыгы – Җирдә тынычлык» балалар рәсеме конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 510 | 510 | 510 | 520 | 520 | 520 |

| Программа чаралары | Башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә, үлчәү берәмлеге | Көтелгән нәтиҗә (еллар буенча) | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
